**Совет**
**Алешкин-Саплыкского**
**сельского поселения**
**Дрожжановского муниципального**
**района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Чүпрәле муниципаль районы**
**Алешкин-Саплык**
**авыл җирлеге**
**Советы**

**422478, Россия, Республика Татарстан, Дрожжановский район, с. Алешкин-Саплык, ул. Школьная, д.3а**
**тел. (84375) 37-5-35, 37-5-49, факс. 37-5-36**
**E-Mail: AlSap.Drz@tatar.ru**

---

Алешкин-Саплык авылы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 август 2023 ел № 39/1

Коррупциячел хокук бозулар кылган өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге Советының 30.01.2013 № 30/1 (05.03.2020 №70/2 редакциясендә) карары белән расланган коррупциячел хокук бозулар кылган өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктның икенче абзацын “федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш.” сүзләре белән тулыландырырга;

2.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“«коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13_4 статьясы нигезендә коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;”.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә..

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы
Алешкин-Саплык авыл җирлеге башлыгы П.Н.Артемьев